**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 3 февраль № 59

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 23 декабрь, 1023 нче карары белән расланган 2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 23 декабрь, 1023 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 22 апрель, 267 нче; 2014 ел, 1 октябрь, 708 нче; 2014 ел, 14 ноябрь, 876 нчы; 2014 ел, 12 декабрь, 977 нче; 2015 ел, 8 апрель, 231 нче; 2015 ел, 19 май, 358 нче; 2015 ел, 1 июнь, 396 нчы; 2015 ел, 16 июнь, 442 нче; 2015 ел, 2 ноябрь, 831 нче; 2016 ел, 24 февраль, 112 нче; 2016 ел, 15 апрель, 225 нче; 2016 ел, 8 май, 288 нче; 2016 ел, 22 июль, 498 нче; 2016 ел, 23 сентябрь, 681 нче; 2016 ел, 30 ноябрь, 884 нче; 2016 ел, 30 декабрь, 1053 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортында:

«Программаның бурычлары» юлында 6 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәтләнүче башка төркемнәре социаль яклау, сәламәтлек саклау, мәдәният, мәгариф, транспорт, мәгълүмат һәм элемтә, физик культура һәм спорт өлкәсендәге өстенлекле объектлардан һәм хезмәтләрдән тоткарлыксыз файдалана алу өчен шартлар тудыру.»;

«Ярдәмче программалар исемлеге» юлында 6 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. 2014 – 2017 елларга «Уңайлы мохит».»;

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr>
<td>«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре</td>
<td>Программаны финанслауның гомуми күләме 171 630 136,044 мең сум тәшкил итә, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 127 318 982,578 мең сум, федераль бюджет акчасы исәбеннән – 44 258 256,800 мең сум, Россия Федерациясе Пенсия фонды бюджетыннан субсидия исәбеннән – 31 719,6 мең сум, бюджеттан тыш чыганаклардан (Тормыш хәле авыр булган балаларга ярдәм күрсәтү фондыннан алынган акча) – 21 177,066 мең сум, шулардан 1 654,537 мең сум – 2013 елда алынган тотылмый калган акча.<br>(мең сум)
<table>
<tr><th rowspan="2">Ел</th><th rowspan="2">Финанслау күләме – барлыгы</th><th colspan="4">Шул исәптән</th></tr>
<tr><th>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы</th><th>федераль бюджет акчасы</th><th>Россия Федерациясе Пенсия фонды бюджетыннан субсидия</th><th>бюджеттан тыш чыганаклар</th></tr>
<tr><td>2014</td><td>20 908 005,515</td><td>15 441 582,078</td><td>5 450 597,7</td><td>14 171,2</td><td>1 654,537</td></tr>
<tr><td>2015</td><td>22 567 805,0</td><td>16 347 332,0</td><td>6 209 073,9</td><td>11 399,1</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2016</td><td>24 563 926,006</td><td>18 346 077,44</td><td>6 202 014,9</td><td>6 149,3</td><td>9 684,366</td></tr>
<tr><td>2017</td><td>24 438 200,323</td><td>18 195 819,66</td><td>6 232 542,5</td><td>-</td><td>9 838,163</td></tr>
<tr><td>2018</td><td>25 369 288,7</td><td>18 907 530,2</td><td>6 461 758,5</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2019</td><td>26 404 974,0</td><td>19 678 283,1</td><td>6 726 690,9</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>27 377 936,5</td><td>20 402 358,1</td><td>6 975 578,400</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>171 630 136,044</td><td>127 318 982,578</td><td>44 258 256,800</td><td>31 719,6</td><td>21 177,066</td></tr>
</table>
Программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш»;</td>
</tr>
</table>

«Еллар буенча бүлеп, Программа максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары)» юлында:

«Татарстан Республикасында өстенлекле объектларның гомуми санында[1] социаль, транспорт, инженерлык инфраструктурасының өстенлекле объектларыннан инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре файдалана ала торган өлешен 44,4 процентка кадәр җиткерергә» сүзләрен «Татарстан Республикасында өстенлекле объектларның гомуми санында социаль, транспорт, инженерлык инфраструктурасының өстенлекле объектларыннан инвалидлар һәм халыкның аз

хәрәкәт итүче башка төркемнәре файдалана ала торган өлешен 2017 елда 54,2 процентка кадәр җиткерергә» сүзләренә алмаштырырга;

«халыкның аз хәрәкәт итүче төркемнәрен йөртү өчен җиһазландырылган гомуми файдаланудагы автомобиль һәм җир өсте шәһәр электр транспортының хәрәкәт итүче составы паркы өлешен Татарстан Республикасында әлеге хәрәкәт итүче состав (автобус, трамвай, троллейбус) паркында 13,4 процентка кадәр җиткерергә» сүзләрен «халыкның аз хәрәкәт итүче төркемнәрен йөртү өчен җиһазландырылган гомуми файдаланудагы автомобиль һәм җир өсте шәһәр электр транспортының хәрәкәт итүче составы паркы өлешен Татарстан Республикасында әлеге хәрәкәт итүче состав (автобус, трамвай, троллейбус) паркында 2017 елда 17,5 процентка кадәр җиткерергә» сүзләренә алмаштырырга;

«системалы рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче 6 яшьтән 18 яшькә кадәрге инвалидларның һәм сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затларның халыкның бу категориясе гомуми санындагы өлешен 54,5 процентка кадәр җиткерергә» сүзләрен «системалы рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче 6 яшьтән 18 яшькә кадәрге инвалидларның һәм сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затларның халыкның бу категориясе гомуми санындагы өлешен 2017 елда 55 процентка кадәр җиткерергә» сүзләренә алмаштырырга;

«Татарстан Республикасында сораштырылган инвалидларның гомуми санында инвалидлар проблемаларына халыкның мөнәсәбәтен уңай бәяләүче инвалидлар өлешен 50,1 процентка кадәр җиткерергә» сүзләрен «Татарстан Республикасында сораштырылган инвалидларның гомуми санында инвалидлар проблемаларына халыкның мөнәсәбәтен уңай бәяләүче инвалидлар өлешен 2017 елда 56,8 процентка кадәр җиткерергә» сүзләренә алмаштырырга;

«социаль яклау өлкәсендәге өстенлекле объектларның гомуми санында инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре файдалана ала торган социаль яклау өлкәсендәге өстенлекле объектлар өлешен 52,4 процентка кадәр җиткерергә» сүзләрен «социаль яклау өлкәсендәге өстенлекле объектларның гомуми санында инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре файдалана ала торган социаль яклау өлкәсендәге өстенлекле объектлар өлешен 2017 елда 62,3 процентка кадәр җиткерергә» сүзләренә алмаштырырга;

«эш белән тәэмин итү хезмәте органнары объектларының гомуми санында инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре файдалана ала торган эш белән тәэмин итү хезмәте органнарының өстенлекле объектлары өлешен 37,4 процентка кадәр җиткерергә» сүзләрен «эш белән тәэмин итү хезмәте органнары объектларының гомуми санында инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре файдалана ала торган эш белән тәэмин итү хезмәте органнарының өстенлекле объектлары өлешен 2017 елда 48 процентка кадәр җиткерергә» сүзләренә алмаштырырга;

«сәламәтлек саклау өлкәсендәге өстенлекле объектларның гомуми санында инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре файдалана ала торган сәламәтлек саклау өлкәсендәге өстенлекле объектлар өлешен 45,4 процентка кадәр җиткерергә» сүзләрен «сәламәтлек саклау өлкәсендәге өстенлекле объектларның гомуми санында инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре

файдалана ала торган сәламәтлек саклау өлкәсендәге өстенлекле объектлар өлешен 2017 елда 55,2 процентка кадәр җиткерергә» сүзләренә алмаштырырга;

«мәдәният өлкәсендәге өстенлекле объектларның гомуми санында инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре файдалана ала торган мәдәният өлкәсендәге өстенлекле объектлар өлешен 36,8 процентка кадәр җиткерергә» сүзләрен «мәдәният өлкәсендәге өстенлекле объектларның гомуми санында инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре файдалана ала торган мәдәният өлкәсендәге өстенлекле объектлар өлешен 2017 елда 46,6 процентка кадәр җиткерергә» сүзләренә алмаштырырга;

«метро станцияләренең гомуми санында инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре файдалана ала торган метро станцияләре өлешен 10,6 процентка кадәр җиткерергә» сүзләрен «метро станцияләренең гомуми санында инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре файдалана ала торган метро станцияләре өлешен 2017 елда 100 процентка кадәр җиткерергә» сүзләренә алмаштырырга;

«транспорт инфраструктурасы өстенлекле объектларының гомуми санында инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре файдалана ала торган транспорт инфраструктурасы өстенлекле объектлары өлешен 56,2 процентка кадәр җиткерергә» сүзләрен «транспорт инфраструктурасы өстенлекле объектларының гомуми санында инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре файдалана ала торган транспорт инфраструктурасы өстенлекле объектлары өлешен 2017 елда 100 процентка кадәр җиткерергә» сүзләренә алмаштырырга;

«өстенлекле объектларның гомуми санында инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре файдалана ала торган физик культура һәм спорт өлкәсендәге өстенлекле объектлар өлешен 49,8 процентка кадәр җиткерергә» сүзләрен «өстенлекле объектларның гомуми санында инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре файдалана ала торган физик культура һәм спорт өлкәсендәге өстенлекле объектлар өлешен 2017 елда 57,7 процентка кадәр җиткерергә» сүзләренә алмаштырырга;

«мәктәп яшендәге инвалид балаларның гомуми санында сыйфатлы башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алу өчен шартлар тудырылган инвалид балалар өлешен 96,0 процентка кадәр җиткерергә» сүзләрен «мәктәп яшендәге инвалид балаларның гомуми санында сыйфатлы башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алу өчен шартлар тудырылган инвалид балалар өлешен 2017 елда 97,0 процентка кадәр җиткерергә» сүзләренә алмаштырырга;

«өстәмә белем алучы 5 яшьтән 18 яшькәчә инвалид балалар өлешен әлеге яшьтәге инвалид балаларның гомуми санында 30,0 процентка кадәр җиткерергә» сүзләрен «өстәмә белем алучы 5 яшьтән 18 яшькәчә инвалид балалар өлешен әлеге яшьтәге инвалид балаларның гомуми санында 2017 елда 35,0 процентка кадәр җиткерергә» сүзләренә алмаштырырга;

«мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының гомуми санында инвалид балаларга, сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балаларга инклюзив белем алу өчен универсаль киртәсез мохит булдырылган мәктәпкәчә белем бирү оешмалары өлешен 16 процентка кадәр җиткерергә» сүзләрен «мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының

гомуми санында инвалид балаларга инклюзив белем алу өчен универсаль киртәсез мохит булдырылган мәктәпкәчә белем бирү оешмалары өлешен 2017 елда 17 процентка кадәр җиткерергә» сүзләренә алмаштырырга;

«мәктәпкәчә белем ала торган 1,5 яшьтән 7 яшькәчә инвалид балалар өлешен әлеге яшьтәге инвалид балаларның гомуми санында 80,0 процентка кадәр җиткерергә» сүзләрен «мәктәпкәчә белем ала торган 1,5 яшьтән 7 яшькәчә инвалид балалар өлешен әлеге яшьтәге инвалид балаларның гомуми санында 2017 елда 85,0 процентка кадәр җиткерергә» сүзләренә алмаштырырга;

«гомуми белем бирү оешмаларының гомуми санында инвалид балаларга инклюзив белем алу өчен универсаль киртәсез мохит булдырылган гомуми белем бирү оешмалары өлешен 21,4 процентка кадәр җиткерергә» сүзләрен «гомуми белем бирү оешмаларының гомуми санында инвалид балаларга инклюзив белем алу өчен универсаль киртәсез мохит булдырылган гомуми белем бирү оешмалары өлешен 2017 елда 22,3 процентка кадәр җиткерергә» сүзләренә алмаштырырга;

«белем бирү оешмаларының гомуми санында инвалид балаларга сыйфатлы белем алу өчен шартлар тудырылган белем бирү оешмалары өлешен 13,5 процентка кадәр җиткерергә» сүзләрен «Россия Федерациясе субъектындагы белем бирү оешмаларының гомуми санында инвалид балаларга сыйфатлы белем алу өчен шартлар тудырылган белем бирү оешмалары өлешен 2017 елда 14 процентка кадәр җиткерергә» сүзләренә алмаштырырга;

Программаның II бүлегендәге егерме икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2014 – 2017 елларга «Уңайлы мохит»;

Программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Программаны финанслауның гомуми күләме 171 630 136,044 мең сум тәшкил итә, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 127 318 982,578 мең сум, федераль бюджет акчасы исәбеннән – 44 258 256,800 мең сум, Россия Федерациясе Пенсия фонды бюджетыннан субсидия исәбеннән – 31 719,6 мең сум, бюджеттан тыш чыганаклардан (Тормыш хәле авыр булган балаларга ярдәм күрсәтү фондыннан алынган акча) – 21 177,066 мең сум, шулардан 1 654,537 мең сум – 2013 елда алынган тотылмый калган акча.

(мең сум)

| Ел | Финанслау күләме – барлыгы | Шул исәптән | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы | федераль бюджет акчасы | Россия Федерациясе Пенсия фонды бюджетыннан субсидия | бюджеттан тыш чыганаклар |
| 2014 | 20 908 005,515 | 15 441 582,078 | 5 450 597,7 | 14 171,2 | 1 654,537 |
| 2015 | 22 567 805,0 | 16 347 332,0 | 6 209 073,9 | 11 399,1 | - |
| 2016 | 24 563 926,006 | 18 346 077,44 | 6 202 014,9 | 6 149,3 | 9 684,366 |
| 2017 | 24 438 200,323 | 18 195 819,66 | 6 232 542,5 | - | 9 838,163 |
| 2018 | 25 369 288,7 | 18 907 530,2 | 6 461 758,5 | - | - |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 2019 | 26 404 974,0 | 19 678 283,1 | 6 726 690,9 | - | - |
| 2020 | 27 377 936,5 | 20 402 358,1 | 6 975 578,4 | - | - |
| Бар-лыгы | 171 630 136,044 | 127 318 982,578 | 44 258 256,800 | 31 719,6 | 21 177,066 |

Программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

Программаның ресурслар белән тәэмин ителеше буенча мәгълүмат әлеге Программага 2 нче кушымтада җентекләп бирелә.»;

Программага 1 нче һәм 2 нче кушымталарны яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәләләр);

«2014 – 2016 елларга «Уңайлы мохит» ярдәмче программасында (алга таба – Ярдәмче программа):

Ярдәмче программа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2014 – 2017 елларга «Уңайлы мохит» ярдәмче программасы»;

Ярдәмче программа паспортында:

«Ярдәмче программа исеме» юлында «2014 – 2016 елларга «Уңайлы мохит» (алга таба – Ярдәмче программа)» сүзләрен «2014 – 2017 елларга «Уңайлы мохит» (алга таба – Ярдәмче программа)» сүзләренә алмаштырырга;

«Ярдәмче программа бурычлары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Ярдәмче программа бурычлары | гражданнарның инвалидлык һәм мөнәсәбәтләрдәге киртәләрне бетерү мәсьәләләрендә хәбәрдар булуы өчен шартлар формалаштыру;<br>өстенлекле объектлардан һәм хезмәтләрдән файдалана алу торышын бәяләү һәм инвалидларның һәм халыкның аз хәрәкәтләнүче башка төркемнәренең тормышында өстенлекле өлкәләрдәге өстенлекле объектлардан һәм хезмәтләрдән файдалана алуын тәэмин итү буенча норматив хокукый һәм методик база булдыру;<br>инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәтләнүче башка төркемнәре социаль яклау, сәламәтлек саклау, мәдәният, мәгариф, транспорт, мәгълүмат һәм элемтә, физик культура һәм спорт өлкәсендәге өстенлекле объектлардан һәм хезмәтләрдән тоткарлыксыз файдалана алу өчен шартлар тудыру»; |

«Ярдәмче программаны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары» юлында «2014 – 2016 еллар» сүзләрен «2014 – 2017 еллар» сүзләренә алмаштырырга;

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм чыга-наклар буенча бү- | Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 804 776,283 мең сум тәшкил итә, шул исәптән Татарстан |

| леп, Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре | Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 427 228,883 мең сум, федераль бюджет акчасы исәбеннән – 377 547,400 мең сум. (мең сум) | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Ел | Акчаның гомуми күләме | Шул исәптән түбәндәгеләр акчасы | |
| | | | Татарстан Республикасы бюджеты | федераль бюджет |
| | 2014 | 526 315,883 | 310 526,383 | 215 789,500 |
| | 2015 | 121 466,000 | 36 439,800 | 85 026,200 |
| | 2016 | 56 496,140 | 16 948,840 | 39 547,300 |
| | 2017 | 100 498,26 | 63 313,86 | 37 184,40 |
| | Барлыгы | 804 776,283 | 427 228,883 | 377 547,400»; |

«Еллар буенча бүлеп, Ярдәмче программа максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары)» юлына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Ярдәмче программа чараларын тормышка ашыру 2017 ел ахырына түбәндәгеләрне арттырырга мөмкинлек бирәчәк:

Татарстан Республикасында өстенлекле объектларның гомуми санында[1] социаль, транспорт, инженерлык инфраструктурасының өстенлекле объектларыннан инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре файдалана ала торган өлешен 2017 елда 54,2 процентка кадәр;

Татарстан Республикасында сораштырылган инвалидларның гомуми санында инвалидлар проблемаларына халыкның мөнәсәбәтен уңай бәяләүче инвалидлар өлешен 2017 елда 56,8 процентка кадәр;

системалы рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче 6 яшьтән 18 яшькә кадәрге инвалидларның һәм сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затларның халыкның бу категориясе гомуми санындагы өлешен 2017 елда 55 процентка кадәр;

социаль яклау өлкәсендәге өстенлекле объектларның гомуми санында инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре файдалана ала торган социаль яклау өлкәсендәге өстенлекле объектлар өлешен 2017 елда 62,3 процентка кадәр;

эш белән тәэмин итү хезмәте органнары объектларының гомуми санында инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре файдалана ала торган эш белән тәэмин итү хезмәте органнарының өстенлекле объектлары өлешен 2017 елда 48 процентка кадәр;

сәламәтлек саклау өлкәсендәге өстенлекле объектларның гомуми санында инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре файдалана ала торган сәламәтлек саклау өлкәсендәге өстенлекле объектлар өлешен 2017 елда 55,2 процентка кадәр;

---

[1] Тереклек эшчәнлегенең һәр өстенлекле өлкәсе буенча шундый ук күрсәткечләр (индикаторлар) хисаплап чыгарылырга мөмкин.

мәдәният өлкәсендәге өстенлекле объектларның гомуми санында инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре файдалана ала торган мәдәният өлкәсендәге өстенлекле объектлар өлешен 2017 елда 46,6 процентка кадәр;

өстенлекле объектларның гомуми санында инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре файдалана ала торган физик культура һәм спорт өлкәсендәге өстенлекле объектлар өлешен 2017 елда 57,7 процентка кадәр;

мәктәп яшендәге инвалид балаларның гомуми санында сыйфатлы башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алу өчен шартлар тудырылган инвалид балалар өлешен 2017 елда 97 процентка кадәр;

өстәмә белем алучы 5 яшьтән 18 яшькәчә инвалид балалар өлешен әлеге яшьтәге инвалид балаларның гомуми санында 2017 елда 35,0 процентка кадәр;

мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының гомуми санында инвалид балаларга инклюзив белем алу өчен универсаль киртәсез мохит булдырылган мәктәпкәчә белем бирү оешмалары өлешен 2017 елда 17 процентка кадәр;

мәктәпкәчә белем ала торган 1,5 яшьтән 7 яшькәчә инвалид балалар өлешен әлеге яшьтәге инвалид балаларның гомуми санында 2017 елда 85 процентка кадәр;

гомуми белем бирү оешмаларының гомуми санында инвалид балаларга инклюзив белем алу өчен универсаль киртәсез мохит булдырылган гомуми белем бирү оешмалары өлешен 2017 елда 22,3 процентка кадәр;

Россия Федерациясе субъектындагы белем бирү оешмаларының гомуми санында инвалид балаларга сыйфатлы белем алу өчен шартлар тудырылган белем бирү оешмалары өлешен 2017 елда 14 процентка кадәр;

халыкның аз хәрәкәт итүче төркемнәрен йөртү өчен җиһазландырылган гомуми файдаланудагы автомобиль һәм җир өсте шәһәр электр транспортының хәрәкәт итүче составы паркы өлешен Татарстан Республикасында әлеге хәрәкәт итүче состав (автобус, трамвай, троллейбус) паркында 2017 елда 17,5 процентка кадәр;

метро станцияләренең гомуми санында инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре файдалана ала торган метро станцияләре өлешен 2017 елда 100 процентка кадәр;

транспорт инфраструктурасы өстенлекле объектларының гомуми санында инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре файдалана ала торган транспорт инфраструктурасы өстенлекле объектлары өлешен 2017 елда 100 процентка кадәр.»;

Ярдәмче программаның I бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«I. Ярдәмче программаны тормышка ашыру өлкәсе тасвирламасы, төп проблемалар һәм аларны хәл итү юллары

Татарстан Республикасы халкының социаль-демографик структурасы үзенчәлеге халыкның гомуми санында инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре чагыштырма авырлыгы югары булуда чагыла. Татарстан Республикасы халкының гомуми санында инвалидлар өлеше 8,1 процент тәшкил

итә, һәм бу сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затларның тереклек эшчәнлеге өчен махсус шартлар булдыру ихтыяҗын тудыра.

2016 елның 1 гыйнвары хәленә карата Татарстан Республикасында 316,0 мең инвалид исәпләнә, шул исәптән 15,0 мең кеше – инвалид балалар, һәм бу Татарстан Республикасы халкының 8 процентыннан артык тәшкил итә, һәм миллионнан артык аз хәрәкәт итүче граждан исәпләнә, яки Татарстан Республикасы халкының якынча 30 проценты. Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре тереклек эшчәнлегенә уңайлы мохит тудыру өчен шартлар булдырырга кирәк, һәм бу аларга үз хокукларын һәм ирекләрен гамәлгә ашырырга, җәмгыятьнең тулы канлы тормышында катнашырга мөмкинлек бирәчәк.

Инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре өчен барлык социаль өлкәләрдә киртәсез мохит шартларын булдыру Россия Федерациясенең бүгенге көнге дәүләт сәясәтенең төп векторларыннан берсе булып тора. 2006 елның 13 декабрендә Берләшкән Милләтләр Оешмасының Генераль Ассамблеясе кабул иткән Инвалидлар хокуклары турында конвенциягә 2008 елда Россия Федерациясе тарафыннан кул кую аның принципларын инвалидларга мөнәсәбәтле дәүләт сәясәтен тормышка ашырганда төп принциплар буларак раслады. Шуңа бәйле рәвештә халыкның аз хәрәкәт итүче төркемнәре өчен киртәсез мохит формалаштыру бурычы халыкка социаль ярдәм күрсәтү буенча формалашкан системаны үстерү өстенлекләренә керә. «Инвалидлар хокуклары турындагы конвенцияне ратификацияләү хакында» 2012 ел, 3 май, ФЗ-46 нчы Федераль закон кабул ителде.

Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан өстенлекле юнәлеш итеп нигездә мөмкинлекләре чикләнгән затлар тереклек эшчәнлегендә чикләүләр формалаштыра һәм аларга социумга тулысынча һәм нәтиҗәле рәвештә кушылып китәргә комачаулый торган «мөнәсәбәт» һәм мохит киртәләрен бетерү мәсьәләләрен беренче чиратта хәл итү зарурлыгы аерып күрсәтелә.

Дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнарының килешеп эшләвен һәм үзара хезмәттәшлек итүен тәэмин итү максатында, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы инвалидлар эшләре советын төзү турында» 2010 ел, 31 декабрь, ПУ-908 нче Указы белән республика инвалидларының проблемалары карап тикшерелә торган Татарстан Республикасы Президенты каршындагы инвалидлар эшләре советы төзелде.

«Инвалидлар хокуклары турында конвенцияне ратификацияләүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына инвалидларны социаль яклау мәсьәләләре буенча үзгәрешләр кертү турында» 2014 ел, 1 декабрь, ФЗ-419 нчы Федераль законны тормышка ашыру кысаларында «Инвалидлар хокуклары хакында конвенцияне ратификацияләүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына инвалидларны социаль яклау мәсьәләләре буенча үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 ел, 9 октябрь, ТРЗ-82 нче Татарстан Республикасы Законы кабул ителде, һәм ул түбәндәге закон актларына – Татарстан Республикасы законнарына инвалидларның объектлардан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән файдалана алуы өчен шартлар тәэмин итү хакында нигезләмәләр өстәүне күздә тота: «Китапханәләр һәм китапханә

эше турында», «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында», «Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру хакында», «Физик культура һәм спорт турында», «Татарстан Республикасында музейлар һәм музей эше хакында», «Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында», «Татарстан Республикасы дәүләт органнары һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары эшчәнлеге хакында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү турында».

Татарстан Республикасы законнары кабул ителде:

«Мәдәният турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 ел, 5 декабрь, ТРЗ-101 нче;

«Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законны гамәлгә ашыру турында» 2015 ел, 26 декабрь, ТРЗ-107 нче;

«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2016 ел, 22 февраль, ТРЗ-8 нче.

Шулай ук «Татарстан Республикасында театрлар һәм театр эше турында» 2016 ел, 11 июнь, ТРЗ-43 нче Татарстан Республикасы Законы кабул ителде, анда да инвалидларның файдалана алуы өчен шартлар тәэмин итү буенча нигезләмәләр бар.

Татарстан Республикасында «Инвалидлар хокуклары турында конвенцияне ратификацияләүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына инвалидларны социаль яклау мәсьәләләре буенча үзгәрешләр кертү турында» 2014 ел, 1 декабрь, ФЗ-419 нчы Федераль законны тормышка ашыру мониторингын оештыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 24 февраль, б-277 нче боерыгы кабул ителде.

Инвалидларның тавыш бирү биналарына тоткарлыксыз керә алуы өчен шартлар тәэмин итүгә, әлеге затларга аларның сайлау хокукларын тормышка ашыру максатларында ярдәм күрсәтүгә бәйле үзгәрешләр 2015 ел, 8 май, ТРЗ-34 нче Татарстан Республикасы Законы белән Татарстан Республикасы Сайлау кодексына, «Татарстан Республикасы референдумы турында» 2003 ел, 9 август, ТРЗ-33 нче, «Җирле референдум турында» 2004 ел, 24 март, ТРЗ-23 нче, «Татарстан Республикасы Президентын чакыртып алу тәртибе турында» 2012 ел, 25 декабрь, ТРЗ-93 нче Татарстан Республикасы законнарына кертелде.

2014 ел, 12 июнь, ТРЗ-53 нче Татарстан Республикасы Законы белән «Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннары квоталау һәм резервлау турында» 2006 ел, 24 июль, ТРЗ-60 нчы Татарстан Республикасы Законына хезмәткәрләре саны 35 кешедән 100 кешегә кадәр булган эш бирүчеләргә инвалидларны эшкә алу өчен квотаны 3 процент күләмендә билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертелде.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 6 декабрь, 954 нче карары белән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының

«Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан оешмаларда инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннарына квоталар билгеләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2007 ел, 4 май, 170 нче карарына үзгәрешләр кертелде.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 20 май, 334 нче карары белән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан эш бирүчеләрдә инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннарын резервка алу тәртибен раслау турында» 2007 ел, 18 май, 194 нче карарына үзгәрешләр кертелде.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары кабул ителде:

«2014 – 2015 елларда эш бирүчегә эш белән тәэмин ителмәгән инвалидны эшкә урнаштыру өчен эш урынын җиһазландыру (адаптацияләү) чыгымнарын каплау тәртибен раслау турында» 2014 ел, 29 октябрь, 795 нче карары;

«2015 – 2020 елларда предприятиеләрдә инвалидларның иҗтимагый берләшмәләре тарафыннан оештырылган инвалидларның эш урыннарын саклауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 23 гыйнвар, 35 нче;

«2015 елда эш бирүчегә инвалидлар хезмәте өчен түләү чыгымнарының бер өлешен каплау тәртибен раслау турында» 2015 ел, 6 апрель, 218 нче.

Татарстан Республикасында тернәкләндерү үткәрүнең төп шартларының берсе тәэмин ителде – дәүләт тернәкләндерү учреждениеләре челтәре төзелде, һәм ул 2016 елның августы хәленә карата 20 тернәкләндерү үзәген (шул исәптән мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен 13 тернәкләндерү үзәге, 6 инвалидларны тернәкләндерү үзәге һәм «Сукырларны һәм начар күрүчеләрне социаль тернәкләндерү республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе), халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәкләр каршындагы 19 социаль-тернәкләндерү бүлеген үз эченә ала, аларның социаль хезмәтләреннән ел саен 15 меңнән артык кеше файдалана. Инвалид балалар өчен тернәкләндерү учреждениеләре социаль хезмәтләрнең түбәндәге төрләрен күрсәтүне үз эченә ала: социаль-көнкүреш, социаль-медицина, социаль-психологик, социаль-педагогик, социаль-хокукый, социаль-хезмәт, коммуникатив потенциалны арттыру максатларындагы хезмәтләр.

Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә дәүләткә карамаган секторны үстерү максатларында, 2010 елдан башлап Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 12 март, 126 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының дәүләткә карамаган оешмалары һәм шәхси эшмәкәрләре тарафыннан Татарстан Республикасы халкына социаль хезмәтләр күрсәтүгә дәүләт заказын формалаштыру тәртибе эшләп килә. Аның нигезендә 2010 елдан 2014 елга кадәр ел саен конкурс нигезендә Түбән Кама шәһәре территориясендә сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балаларга һәм яшүсмерләргә (инвалид балаларга) тернәкләндерү хезмәтләре күрсәтүгә, 2012 елдан 2014 елга кадәр – Чаллы шәһәре территориясендә һәм 2013 елдан 2014 елга кадәр – Казан шәһәре территориясендә өлкән яшьтәге гражданнарга, шул исәптән инвалидларга тернәкләндерү хезмәтләре күрсәтүгә дәүләт заказы урнаштырылды.

Сатуларның җиңүчеләре белән социаль хезмәтләр күрсәтүгә дәүләт контрактлары төзелде.

2015 – 2016 елларда 2013 ел, 28 декабрь, «Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында» ФЗ-442 Федераль закон, «Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2014 ел, 18 декабрь, ТРЗ-126 нчы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итүчеләр реестрын һәм социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучылар регистрын төзү һәм алып бару турында» 2014 ел, 23 декабрь, 1012 нче карары нигезендә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының рәсми сайтында урнаштырылган Социаль хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итүчеләр реестры формалаштырылды.

2017 елның 1 гыйнвары хәленә карата Татарстан Республикасының социаль хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итүчеләр реестрына түбәндәге дәүләткә карамаган оешмалар кертелгән:

«Крутушка шифаханәсе» ачык акционерлык җәмгыяте;

Чаллы шәһәренең «Хезмәт ветераннары өчен пансионат» муниципаль автоном учреждениесе;

«Надежда» Түбән Кама махсус (коррекцияле) гомуми белем бирү VI төр интернат мәктәбе» сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән укучылар өчен муниципаль автоном махсус (коррекцияле) белем бирү учреждениесе;

«Чудо-дети» дәвалау педагогикасы үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы.

Социаль хезмәтләр дәүләткә карамаган оешмаларда социаль хезмәт күрсәтүнең стационар һәм ярымстационар формаларында күрсәтелә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр реестрына кертелгән, әмма дәүләт йөкләмәсен (заказын) үтәүдә катнашмый торган социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан компенсация түләү тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип санау турында» 2016 ел, 29 декабрь, 1046 нчы карары нигезендә Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр реестрына кертелгән, әмма дәүләт йөкләмәсен (заказын) үтәүдә катнашмый торган социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләргә түләүсез яки өлешчә түләп социаль хезмәтләр күрсәтү белән бәйле чыгымнарын компенсацияләүгә (каплауга) субсидия рәвешендә грант бирелә.

Республикада инвалид балаларга белем бирүне оештыруга системалы якын килү гамәлгә ашырыла. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 17 сентябрь, 688 нче карары белән 2015 – 2018 елларга Татарстан Республикасы социаль сәясәтендә инклюзияне үстерү концепциясе расланды.

Республиканың мәгариф оешмаларында инвалид балаларның һәм үсешендә тоткарлыклар булмаган балаларның бергәләп укуын тәэмин итүче шартлар булдыру буенча актив эш алып барыла.

Инвалид балаларны укыту шартларын булдыру чаралары 138 гомуми белем бирү оешмасында, 5 мәктәпкәчә белем бирү оешмасында һәм 12 махсус (коррекцияле) белем бирү оешмасында башкарылды.

«Татарстан Республикасының Мәгарифне үстерү институты» дәүләт автоном өстәмә һөнәри белем бирә торган мәгариф учреждениесе тарафыннан «Инклюзив белем бирү шартларында мөмкинлекләре чикләнгән балаларга булышлык күрсәтү» модуле эшләнде.

Казан шәһәренең Идел буе районы «78 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе базасында инклюзив белем бирүнең ресурс үзәге төзелде.

Татарстан Республикасының 52 махсус (коррекцияле) белем бирү оешмасы базасында сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм инвалид балалар белән эшләүне оештыру буенча уку-укыту-методик ресурс үзәкләре төзелә.

Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән укучыларга башлангыч гомуми белем бирүнең федераль дәүләт мәгариф стандартын раслау турында» 2014 ел, 19 декабрь, 1598 нче, «Акылы зәгыйфь (интеллектуаль тайпылышлар) булган укучыларга белем бирүнең федераль дәүләт мәгариф стандартын раслау турында» 2014 ел, 19 декабрь, 1599 нчы боерыклары нигезендә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан 2016 елның 1 сентябреннән сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затлар өчен федераль дәүләт мәгариф стандартларын гамәлгә кертү буенча «юл картасы» эшләнде.

Татарстан Республикасында инвалид балаларның мәктәпкәчә белемгә хокукларын яклау тәэмин ителгән 1 890 мәктәпкәчә белем бирү оешмасы эшләп килә, 52 махсус (коррекцияле) учреждение төзелде, 1,5 меңнән артык бала өйдә укыту формасына җәлеп ителгән, гомуми белем бирү оешмаларында инвалид балаларны дистанцион укыту формасы актив рәвештә үстерелә.

Инвалидлыгы булган затларның 69 һөнәри белем бирү оешмасында уку мөмкинлеге бар.

Инклюзив сәясәтнең төбәк моделе шәхси мәсьәләләрне хәл итүне дә, тулаем иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең яңа культурасын – инклюзив культураны формалаштыруны да күздә тота.

2011 елда А.Н.Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты каршында Ишетү буенча сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затларны һөнәри тернәкләндерү буенча Казан уку-укыту-тикшеренү һәм методик үзәге төзелде. Әлеге үзәк «Саунд» ЯАҖ белән хезмәттәшлек иткәндә программалаштырыла торган санлы «Бекар» ишетү-сөйләү тренажерлары һәм «Бекар-С» өйрәтү стендлары эшләнде, һәм аларның кайбер мөһим өстенлекләре бар: сөйләмдә мәгълүматны тапшыруның югары нәтиҗәлелеге, мөстәкыйль тренинг мөмкинлеге, кешенең калдык ишетү мөмкинлекләренә яңа технологиянең сакчыл мөнәсәбәте, конструкциянең гадилеге һәм ышанычлылыгы.

Начар ишетүче һәм чукрак балаларның ишетеп кабул итүен һәм авазларны дөрес әйтүен үстерү өчен методик материаллар комплекты белән «Ишетелгәнне ишетү, кабул итү һәм сөйләү» комплекслы методикасы төзелде.

Хәзерге вакытта А.Н.Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университетында начар ишетүче һәм чукрак студентлар биш юнәлеш буенча укый: радиотехника; мәгълүмат технологияләре һәм элемтә системалары; материаллар

фәне һәм материаллар технологиясе; машина төзелеше; электроника һәм наноэлектроника. 2016 елда начар ишетүчеләр һәм чукраклар арасыннан 16 студент чыгарылышы гамәлгә ашырылды.

Белем бирү баскычлары арасында эзлеклелекне оештыру максатларында, хәзерге вакытта «Ишетелгәнне ишетү, кабул итү һәм сөйләү» комплекслы методикасы һәм эшләнгән «Бекар» ишетү-сөйләү тренажерлары «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Е.Г.Ласточкина исемендәге Казан интернат мәктәбе» дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең белем бирү процессына кертелде.

Татарстан Республикасында «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затлар белән эшләү буенча республика югары уку йортлары үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы төзелде, аның составына югары белем бирүче мәгариф оешмалары һәм Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы вәкилләре керде. Эксперт төркеме комиссияләр һәм эшчәнлек юнәлешләре буенча бүленгән, шуларның берсе булып эш белән тәэмин итү тора.

Татарстан Республикасында 5 ел дәвамында һәркем файдалана алырлык медицина ярдәменең югары күрсәткечләре саклана, авыл торак пунктларында медицина ярдәме дәрәҗәсе күтәрелгән. Эзлекле рәвештә махсуслаштырылган һәм югары технологияле медицина юнәлешләре үстерелә, мәсәлән, кардиохирургия, нейрохирургия, эндопротезлау, онкология.

Республикада инвалидлар, ветераннар һәм өлкән гражданнарның сәламәтлеген саклауга, медицина һәм дарулар ярдәменең һәркем файдалана алуын һәм сыйфатын яхшыртуга юнәлдерелгән өстәмә чаралар гамәлгә ашырыла.

Аз хәрәкәт итүче гражданнар һәм ерак авыл җирлекләрендә яшәүче гражданның медицина ярдәменнән файдалана алуын тәэмин итү максатларында, медицина ярдәме күрсәтү, шул исәптән махсуслаштырылган, өйгә килеп, комплекслы диспансер тикшерүләре үткәрү тәэмин ителә. Әлеге максатларда территориаль сәламәтлек саклау учреждениеләре базасында мобиль табиблар бригадалары формалаштырылды, шул исәптән авыл җирлекләрендә яшәүчеләргә хезмәт күрсәтү өчен.

Халкы саны 100 кешедән азрак булган ераклашкан торак пунктларда йорт хуҗалыклары оештырылды. Аларның һәрберсендә беренче медицина ярдәме күрсәтергә өйрәтелгән һәм медицина кирәк-яраклары салынган сумка белән җиһазландырылган җаваплы зат була.

Махсуслаштырылган медицина ярдәме күрсәтү дәрәҗәләрен һәм тәртипләрен исәпкә алып, медицина ярдәменең төрле профильләре буенча авыруларның маршрутлары билгеләнгән.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 1 июль, 461 нче карары белән расланган «2020 елга кадәр Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын үстерү» дәүләт программасына «Медицина тернәкләндерүен һәм шифаханә-курорт дәвалавын (шул исәптән балаларны) үстерү» ярдәмче программасы кертелде.

Соңгы елларда республикада спорт объектлары, шул исәптән Казан шәһәрендә 2013 елгы XXVII Бөтендөнья җәйге универсиадасын үткәрү чорында җәлеп ителгән объектлар адаптацияләнде. Инвалидлар әлеге объектларга тамашачылар

сыйфатында да, ярышларда катнашучылар буларак та бара ала. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика балалар-яшүсмерләр спорт-адаптация мәктәбе» дәүләт бюджет өстәмә белем бирү учреждениесен оештыру турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1086 нчы карары нигезендә Татарстан Республикасында балалар-яшүсмерләр спорт-адаптация мәктәбе ачылды, һәм аның төп эшчәнлек максаты булып инвалидлар һәм сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затларның социаль адаптациясе һәм аларны физик тернәкләндерү тора. Беренче этапта спортның 8 паралимпия һәм сурдлимпия төрен үстерү планлаштырылган: бочча, пара-ишү, чаңгы ярышлары, өстәл теннисы, керлинг, йөзү, җиңел атлетика, ирекле көрәш. Дәресләр Казан шәһәре һәм Зеленодольск шәһәренең спорт комплекслары: Су спорты төрләре сарае, «Буревестник», «Олимп», Үзәк стадион, «Маяк» (Зеленодольск шәһәре) һәм гомуми белем бирү учреждениеләре – «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Е.Г.Ласточкина исемендәге Казан интернат мәктәбе» дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе базасында оештырыла.

Алга таба волейбол, голбол, коляскаларда баскетбол, грек-рим көрәше, дзюдо, өстәл теннисы, пауэрлифтинг, футбол кебек спорт төрләрен үстерү планлаштырыла.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 23 декабрь, 1023 нче карары белән расланган 2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасының «Уңайлы мохит» ярдәмче программасын (алга таба – Ярдәмче программа) тормышка ашыру кысаларында, 2014 елда Татарстан Республикасы җыелма командаларының инвалид спортчылары өчен тулысынча җиһазландырылган махсус автобус сатып алынды. Ярдәмче программа кысаларында 2015 елда инвалид балаларны йөртү өчен 4 махсуслаштырылган автобус сатып алынды (Түбән Кама шәһәре, Зеленодольск шәһәре, Саба, Арча муниципаль районнары өчен).

Хәзерге җәмгыятьтә мөмкинлекләре чикләнгән кешеләргә (беренче чиратта балаларга һәм яшьләргә) гомуми белем бирү процессы, төрле чорларның мәдәни истәлекләре белән таныштырырга ярдәм итә торган музей программалары һәм экспозицияләр актуальләшә бара. Мондый тәҗрибә җәмгыятьнең толерантлыгын үстерергә, «киртәсез» социомәдәни мохит булдырырга, күрү буенча сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән кешеләрнең социаль адаптациясенә мөмкинлек бирә. 2014 елда Ярдәмче программаны тормышка ашыру кысаларында тактиль музей экспонатлары эшләнде: чын археологик һәм этнографик предметларның күчмә витриналарда урнаштырылган күләмле күчермәләре (репликалары), архитектура истәлекләренең кече күчермәләре.

Максатчан тернәкләндерү эше Сукырлар өчен махсус республика китапханәсе тарафыннан алып барыла. Мәгълүмат-китапханә хезмәтләре ишетү буенча барлык яшь төркемендәге 4000нән артык инвалидка, аларның гаилә әгъзаларына, авырулары гомуми файдаланудагы китапханәләрдән файдаланырга һәм басма документларны укырга комачаулаган инвалидларның башка категорияләренә, шулай ук инвалидлар һәм инвалидлык проблемалары белән һөнәри шөгыльләнүче

физик һәм юридик затларга күрсәтелә. Китапханәдә барлык хезмәтләр түләүсез күрсәтелә. Китапханәдә тифлокомментарийле кинофильмнар карау оештырылган.

Махсус китапханәдә сукыр булган файдаланучыларны мәгълүмат технологияләренә өзлексез өйрәтү системасы төзелде (компьютер белеме, Nokia смартфоннары, Apple сенсорлы җайланмалары базасында GPS-навигация курслары; «Apple персональ компьютеры» гомуми курсы).

Начар күрүчеләр өчен китаплар бастыру һәм «сөйли торган» китаплар төзү буенча автоматлаштырылган комплекс булдыруга җиһазлар сатып алу сукырлар һәм начар күрүчеләр өчен китапларның бөтен төп форматларын (зурайтылган шрифт, кабарынкы-ноктала Брайль шрифты белән, кабарынкы-график китаплар, тактиль китаплар, «сөйли торган» китаплар) репродукция ясау, житештерү һәм тиражлау өчен мөмкинлек бирә. Комплекс китапханәгә мөстәкыйль рәвештә китапханә фондларын тулыландырырга мөмкинлек бирә, шул исәптән рус һәм татар телләрендә.

Аз хәрәкәт итүче гражданнар өчен файдалана алу мөмкинлеген булдыру максаты белән шулай ук «Мир» кинотеатрын адаптацияләү эшләре үткәрелде: объектка бару юлларын уңайлаштыру, парковка урыннарын булдыру, пандус, тактиль плитә куеп, кирә торган төркемне җиһазландыру, объект эчендә йөрү юлларын адаптацияләү, санитария-гигиена бүлмәләрен җиһазландыру, ишекләр куеп, ишек уелган урыннарны киңәйтү, тоткычлар кую, коляскада йөрүче инвалидлар өчен кинофильм карау зонасын уңайлаштыру. Тамашачылар залы начар күрүчеләр арасында кинофильм карауны, матрица үзгәрү ысулларын кулланмыйча, начар ишетүчеләр өчен колак аппаратына сыйфатлы тавыш сигналы алуны һәм колак аппаратлары кигән тамашачыларга заманча фильмнарны стереотавыш белән ялгышларсыз тулы канлы карауны тәэмин итәргә мөмкинлек бирә торган махсус җайланма белән җиһазландырылган.

Әлеге кинотеатрда фильм күчермәләрен тифлокомментарийләр һәм субтитрлар белән карауны оештырырга мөмкинлек бирә торган BarcoDP2K-12C кинопроекторы һәм GDCSX2000A серверы куелган.

Инвалидлар өчен уңайлы яшәү мохит формалаштыру Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерүнең өстенлекле бурычларының берсе булып тора.

2011 елда Татарстан Республикасы уңайлы мохит тудыру һәм тиешле инновацион методикаларны эшләү буенча масштаблы эшләр үткәрү өчен Россиядә беренче пилот төбәге булды.

2011 – 2015 елларда объектларны адаптацияләүгә якынча 2,5 млрд.сум юнәлтелде, әлеге еллар эчендә барлыгы 709 объект адаптацияләнде, шул исәптән сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният, физик культура һәм спорт, социаль яклау һәм эш белән тәэмин итү учреждениеләре (410 социаль өлкә объекты һәм 299 мәгариф өлкәсе объекты).

Шулай ук республика шәһәрләрендә җәяүлеләр чыгу урыннары (җир өсте, җир асты һәм җирдәге) яңадан җиһазландырылды.

Коляскада йөрүче инвалидлар яши торган торак фондын (1 710 подъезд) һәм күрү буенча инвалидлар җыелып яши торган торак йортларны (2011 ел – 2 йорт,

2012 ел – 28 йорт) адаптацияләү буенча зур күләмле эш башкарылды.

Һәр объектта барлык категорияләрдәге: терәк-хәрәкәт аппараты зарарланган, ишетү һәм күрү сәләте бозылган инвалидлар өчен объектка керә алу мөмкинлеген булдыру һәм хезмәт күрсәтү буенча чаралар каралды.

Республиканың башкарма хакимият органнары, муниципаль районнары һәм шәһәр округлары сайтлары күрү сәләте бозылган кешеләр өчен адаптацияләнгән.

Моннан тыш, халыкның аз хәрәкәт итүче төркемнәре өчен социаль, транспорт һәм инженерлык инфраструктурасы объектларыннан файдалана алу мөмкинлегенең мәгълүматлар банкын һәм картасын формалаштыру һәм үстерү буенча программа продукты эшләнде һәм сәнәгатьтә кулланылышка кертелде. Инвалидлар өчен файдалану картасы – социаль, административ, мәдәни һәм башка объектлар билгеләнә торган бердәм карта.

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, «Татдорпроект» ААҖ, Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы белән берлектә, инвалидлар өчен уңайлы мохит формалаштыру нигезләре, муниципаль берәмлекләрдәге өстенлекле объектлар исемлеген билгеләү, гамәлдәге социаль, транспорт һәм инженерлык инфраструктурасы объектларын паспортлаштыруны үткәрү, муниципаль берәмлекләрдә инвалидларга объектлардан һәм хезмәтләрдән файдалана алу мөмкинлеге күрсәткечләре мәгънәләрен күтәрү буенча чаралар планнарын («юл карталарын») эшләү буенча җирле үзидарә органнарының эшче төркемнәрен, дәүләт хакимияте органнары белгечләрен, инвалидларның иҗтимагый оешмалары вәкилләрен укытулар үткәрелде.

Әлеге Ярдәмче программа инвалидларны тернәкләндерү һәм аларның җәмгыятькә интеграциясе, инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче төркемнәре өчен социаль, транспорт һәм инженерлык инфраструктурасы объектларының һәм хезмәтләрнең файдалана алырлык булуын арттыру, аларның яшәү дәрәҗәсен һәм сыйфатын күтәрү өчен шартлар тудыру буенча Татарстан Республикасында үткәрелә торган комплекслы чараларның дәвамы булды.

Ярдәмче программа чараларын тормышка ашыру нәтиҗәсендә 2015 ел ахырына Татарстан Республикасындагы өстенлекле объектларның гомуми санында инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре файдалана ала торган социаль, транспорт, инженерлык инфраструктурасының өстенлекле объектлары өлеше 41 процентка җитте.

2016 елда Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 56 496,14 мең сум тәшкил итте (федераль бюджеттан – 39 547,30 мең сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан – 16 948,84 мең сум).

Ярдәмче программада инвалидларның барлык категорияләренә игътибар бирелгән, һәр объектта терәк-хәрәкәт аппараты зарарланган, ишетү һәм күрү сәләте бозылган инвалидлар өчен объектка керә алу мөмкинлеген булдыру һәм хезмәт күрсәтү буенча чаралар каралган.

Ярдәмче программа инвалидларның тереклек эшчәнлегендәге төп өстенлекле өлкәләрне үз эченә алды, аның кысаларында 46 объектта адаптацияләү эшләре үткәрелде, шул исәптән:

3 социаль яклау объектында;

17 сәламәтлек саклау объектында;

10 спорт өлкәсендәге объектта;

6 мәдәният өлкәсендәге объектта;

10 мәгариф оешмасында (5 гомуми белем бирү һәм 5 мәктәпкәчә белем бирү оешмасы).

Адаптив спортны үстерү өчен уңай шартлар булдырылды (спорт инвентаре һәм җиһазлар сатып алынды).

Әлеге Ярдәмче программа кысаларында чукракларга кичектергесез һәм башка социаль ярдәм күрсәтү максаты белән алар өчен тәүлек буе эшли торган диспетчерлык элемтә үзәкләренә 2016 елда җиһазлар сатып алынды.

2016 елда республиканың бөтен муниципаль берәмлекләрендә социаль инфраструктура объектларын паспортлаштыру һәм файдалану картасының мәгълүматлар банкын актуальләштерү эше дәвам иттерелде. 2016 елның 31 декабренә файдалану картасына 5 218 объект турында мәгълүмат кертелде.

2016 ел ахрына индикатор «Татарстан Республикасындагы өстенлекле объектларның гомуми санында инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре файдалана ала торган социаль, транспорт, инженерлык инфраструктурасының өстенлекле объектлары өлеше» арттырып үтәлде (44,6 процент, план буенча – 44,4 процент).

Әлеге Ярдәмче программа кысаларында республикада 2017 елда түбәндәге бурычлар хәл ителәчәк:

гражданнарның инвалидлык һәм мөнәсәбәтләрдәге киртәләрне бетерү мәсьәләләрендә хәбәрдар булуы өчен шартлар формалаштыру;

өстенлекле объектлардан һәм хезмәтләрдән файдалана алу торышын бәяләү һәм инвалидларның һәм халыкның аз хәрәкәтләнүче башка төркемнәренең тормышында өстенлекле өлкәләрдәге өстенлекле объектлардан һәм хезмәтләрдән файдалана алуын тәэмин итү буенча норматив хокукый һәм методик база булдыру;

инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәтләнүче башка төркемнәре социаль яклау, сәламәтлек саклау, мәдәният, мәгариф, транспорт, мәгълүмат һәм элемтә, физик культура һәм спорт өлкәсендәге өстенлекле объектлардан һәм хезмәтләрдән тоткарлыксыз файдалана алу өчен шартлар тудыру.

Әлеге Ярдәмче программаның нигез булып торган юнәлеше – социаль, транспорт һәм инженерлык инфраструктурасында инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче төркемнәре өчен уңайлы мохит формалаштыруның норматив хокукый тәэминатын булдыру; инвалидлар социаль һәм транспорт инфраструктураларыннан файдалана алуны тәэмин итүне тикшерүдә тоту һәм мониторинг системасын формалаштыру.

Тиешле юнәлештәге чаралар үз эченә түбәндәгеләрне ала:

инвалидларның гамәлдәге социаль, транспорт һәм инженерлык инфраструктурасы объектларыннан файдалана алуын тәэмин итү буенча чараларның минималь исемлеген эшләү;

гамәлдәге социаль, транспорт һәм инженерлык инфраструктурасы объектларын паспортлаштыруны үткәрү өчен җирле үзидарә органнарының эшче төркемнәрен укытуны үткәрү;

терәк-хәрәкәт аппараты, күрү һәм ишетү сәләте бозылган инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре өчен уңайлы мохит тудыруны регламентлаштыра торган методик тәкъдимнәр эшләү һәм нәшер итү; терәк-хәрәкәт аппараты, күрү һәм ишетү сәләте бозылган инвалидлар файдалана ала торган социаль, транспорт һәм инженерлык инфраструктураларын төзү (методик материалларны интернет-сайтта урнаштырып).

Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләренә, төрле милек формасындагы учреждениеләргә һәм оешмаларга методик ярдәм күрсәтү максатларында, түбәндәге чаралар үтәлә:

инвалидлар тереклек эшчәнлегенә уңайлы мохит формалаштыруның муниципаль максатчан программаларын төзү буенча методик тәкъдимнәр эшләү;

социаль һәм транспорт инфраструктурасы объектларыннан файдалана алу мөмкинлегенең мәгълүматлар банкын һәм картасын төзү өчен программа продуктын, шулай ук инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре өчен өстенлекле объектларны паспортлаштыру нәтиҗәләре буенча формалаштырылачак инвалидларның социаль, транспорт һәм инженерлык инфраструктурасыннан файдалана алуын тәэмин итүне тикшерүдә тоту системасын эшләү һәм гамәлгә кертү.

Методик ярдәм белән беррәттән, инвалидларның социаль инфраструктура объектларыннан һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән, дәүләт һәм муниципаль торак фондыннан файдалана алуына карата таләпләрнең үтәлешен тикшерүдә тоту тәэмин ителгән, тикшерүләр нәтиҗәләре буенча – Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгына ай саен мәгълүмат тапшыру (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 24 февраль, б-277 нче боерыгы).

Ярдәмче программа кысаларында инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче төркемнәре өчен уңайлы мохит тудыру буенча гамәли чаралар тормышка ашыру социаль, транспорт һәм инженерлык инфраструктурасының өстенлекле өлкәләрендә башкарылды.

Уңайлы мохит формалаштырганда комплекслы якын килү күрү, ишетү сәләте һәм терәк-хәрәкәт аппараты бозылган инвалидларның индивидуаль ихтыяҗларын исәпкә алу юлы белән тәэмин ителде.

Инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре өчен социаль, транспорт һәм инженерлык инфраструктурасы объектларында уңайлы мохит формалаштыру буенча гамәли чаралар үз эченә түбәндәге чараларны алды:

социаль, транспорт һәм инженерлык инфраструктурасының өстенлекле өлкәләрендә биналарны адаптацияләү;

инвалидларның һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәренең аерым ихтыяҗларын исәпкә алып, аларның пассажирлар транспортының хәрәкәт итүче

составыннан файдалана алуын тәэмин итү, инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре файдалана алуны тәэмин итә торган махсус җиһазлы һәм конструктив үзенчәлекле транспорт чаралары сатып алу;

җәяүлеләр чыгу урыннарына, җәмәгать пассажирлар транспорты тукталышларына пандуслар кую, җәяүлеләр чыгу урыннарында төшү/чыгу уңайлыгы өчен юл каймасындагы ташны тактиль һәм контраст өслекләр һ.б. белән тәбәнәкләндерү; тукталыш мәйданчыкларында маршрут автобусларының якынча килү вакыты турында сорау буенча (чакыру төймәсе) тавыш белән хәбәр итә торган мәгълүмати таблолар кую; тавышлы светофорлар кую;

инвалидларның бөтен категорияләре өчен Казан метрополитенының 10 станциясен җиһазландыру (мәгълүмати таблолар һәм хәбәр итү чаралары кую, рельефлы (тактиль) полосалар, контраст полосалар һәм билгеләр, идәндә ныгыткычлар, ябылу җайланмалары урнаштыру, күтәрткечләр кую), Казан метрополитенының эксплуатациягә 2013 елда кертелгән калган 3 станциясендә киләсе елларда хезмәтләрдән файдалана алу мөмкинлеген арттыру чаралары үткәрелде;

инвалидларның аерым ихтыяҗларын исәпкә алып, гомуми белем бирү учреждениеләренә, һөнәри белем бирү учреждениеләренә тоткарлыксыз керә алуын тәэмин итү; социаль өлкә учреждениеләре хезмәткәрләрен сурдотәрҗемәгә өйрәтү.

Казан муниципаль берәмлеге бюджеты акчасы исәбеннән 2011 елның 1 декабреннән «Уңайлы мохит» проектын тормышка ашыру кысаларында мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр өчен Казан шәһәре районнарындагы социаль яклау бүлекләрендә һәм Бөтенроссия чукраклар җәмгыяте Татар иҗтимагый оешмасының иҗтимагый оешмасы офисында элемтәдә сурдотәрҗемәче булган видеотелефоннар кую башкарылды.

«Бөтенроссия чукраклар җәмгыяте» инвалидларның гомумроссия иҗтимагый оешмасының Татар республика бүлеге тарафыннан 2012 елдан башлап Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының грант ярдәме белән «Бу үзәктә сине ишетерләр һәм аңларлар» социаль проекты гамәлгә ашырыла.

«Бу үзәктә сине ишетерләр һәм аңларлар» проектын гамәлгә ашыру кысаларында, ишетү буенча инвалидларга киртәләрсез мохит тудыру һәм төрле хезмәтләрдән (ашыгыч медицина ярдәме, ГТХМ, полиция, янгын куркынычсызлыгы хезмәте, ТКХ хезмәтләре, белешмә хезмәтләре) файдалана алуларын тәэмин итү максатларында, ишетү буенча мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр һәм ишетүче кешеләр арасында диспетчер (сурдотәрҗемәче-оператор) ярдәмендә скайп, факс, sms-хәбәрләр яки электрон почта аша коммуникатив элемтә тормышка ашырыла, шулай ук ишетү буенча инвалидларны эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтелә. Ел саен «Бөтенроссия чукраклар җәмгыяте» инвалидларның гомумроссия иҗтимагый оешмасының Татар республика бүлегенә әлеге проектны тормышка ашыруга грант ярдәме күрсәтелә. Диспетчерлык хезмәтләре Казан, Зеленодольск, Чаллы шәһәрләрендә эшләп килә.

2016 елда «Бөтенроссия чукраклар җәмгыяте» инвалидларның гомумроссия иҗтимагый оешмасының республика бүлегенә грант ярдәме рәвешендә 157 268 сум бирелде. Диспетчерлык элемтә пункты эшләве өчен 2016 елда ишетү буенча

инвалидларга кичектергесез һәм башка социаль ярдәм күрсәтү максаты белән җиһазлар сатып алынды.

«Ачык Татарстан» проекты кысаларында Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталында «Халык контроле» проекты тормышка ашырыла. Проект кысаларында төзелгән «Уңайлы мохит» бүлеге файдаланучыга теләсә кайсы объекттан файдалана алу мөмкинлеге турында хәбәрнамә калдырырга һәм дәүләт хакимияте яки муниципаль хакимият органнары кабул иткән карар сыйфатын бәяләргә мөмкинлек бирә.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Инвалидларның ихтыяҗларын исәпкә алып, күпфатирлы йорттагы торак урыннарны һәм уртак мөлкәтне уңайлаштыру чаралары турында» 2016 ел, 9 июль, 649 нчы карары белән Инвалидларга күпфатирлы йорттагы торак урыннардан һәм уртак мөлкәттән файдалана алу шартларын тәэмин итү кагыйдәләре расланды.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт торак фонды, муниципаль торак фонды, шулай ук хосусый торак фонды составына керә торган торак урыннарга мөнәсәбәтле, инвалидларның ихтыяҗларын исәпкә алып, инвалидларның торак урыннарын уңайлаштыру чараларын яраштыру буенча Татарстан Республикасының вәкаләтле башкарма хакимият органын билгеләү турында» 2016 ел, 20 декабрь, 958 нче карары белән Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы Татарстан Республикасы дәүләт торак фонды, муниципаль торак фонды, шулай ук хосусый торак фонды составына керә торган торак урыннарга мөнәсәбәтле, инвалидларның ихтыяҗларын исәпкә алып, инвалидларның торак урыннарын уңайлаштыру чараларын яраштыру буенча Татарстан Республикасының вәкаләтле башкарма хакимият органы итеп билгеләнде.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 28 сентябрь, 716 нчы карары белән 2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасында инвалидлар өчен объектларның һәм хезмәтләрнең һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре мәгънәләрен күтәрүгә юнәлдерелгән чаралар планы («юл картасы») расланды, һәм анда инвалидларның, хезмәтләрдән файдаланганда, башка затлар белән беррәттән тигез мөмкинлекләрен тәэмин итүгә, аларның социаль һәм мәдәни тормышта катнашуын киңәйтүгә юнәлдерелгән чаралар каралган.

Әлеге Ярдәмче программаны тормышка ашыру чорында түбәндәге проблемалар ачыкланды:

1. Файдалана алу мөмкинлегенә карата таләпләрне үтәү өлешендә норматив хокукый кырның балансы булмавы.

2. Барлык этапларда – объектны проектлаштырудан башлап эксплуатациягә керткәнгә кадәр файдалана алу мөмкинлегенә карата таләпләрне үтәүгә контрольнең катгый системасы булмау.

3. Яңа биналар проектлаштыру һәм төзү, эксплуатациядә булган гамәлдәге биналарны адаптацияләү өлешендә проектлаштыручыларның һәм төзүчеләрнең компетенциясе җитәрлек дәрәҗәдә булмау.

4. Материаллар һәм җиһазлар базарының камил булмавы, уңайлы мохит булдыру өчен кирәкле сыйфатлы материаллар һәм җиһазлар җитештерүенең үсеш алмавы.

5. Файдалану элементларын хәзерге вакытта карап тоту һәм эксплуатациягә кертү өчен финанс чыгымнары учреждениеләр бюджетында каралмаган һәм учреждениеләрнең штат хезмәткәрләренең өстәмә бәрәмлекләре белән тәэмин ителмәгән.

Әлеге Ярдәмче программаны эшләү өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 ел, 24 ноябрь, ФЗ-181 нче Федераль закон;

«Инвалидлар хокуклары турында конвенцияне ратификацияләүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына инвалидларны социаль яклау мәсьәләләре буенча үзгәрешләр кертү турында» 2014 ел, 1 декабрь, ФЗ-419 нчы Федераль закон;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2011 – 2020 елларга «Уңайлы мохит» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2015 ел, 1 декабрь, 1297 нче карары;

2020 елга кадәр чорга Россия Федерациясенең озак вакытлы социаль-икътисадый үсеш концепциясе (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2008 ел, 17 ноябрь, б-1662 нче боерыгы белән расланды);

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Россия Федерациясе субъектының инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре тереклек эшчәнлегенең өстенлекле өлкәләрендәге өстенлекле объектлардан һәм өстенлекле хезмәт күрсәтүләрдән файдалана алуны тәэмин итү буенча якынча программасын раслау турында» 2012 ел, 6 декабрь, 575 нче боерыгы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы инвалидлар эшләре советын төзү турында» 2010 ел, 31 декабрь, ПУ-908 нче Указы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлеген һәм Татарстан Республикасының дәүләт программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 21 декабрь, 1199 нчы карары.

Әлеге Ярдәмче программаны тормышка ашыру кысаларында әһәмиятле момент булып аны үтәү барышында килеп чыгарга һәм аның нәтиҗәләренә тискәре йогынты ясарга мөмкин булган куркынычларны минимальләштерү тора, аерым алганда:

бюджет дефициты барлыкка килүгә һәм шуның нәтиҗәсендә бюджет финанславының җитәрлек дәрәҗәдә бумавына бәйле финанс куркынычы;

финанс ресурсларыннан нәтиҗәле файдаланмау куркынычы;

Ярдәмче программа белән нәтиҗәле идарә итмәү куркынычы:

Ярдәмче программаны үтәү барышында нәтиҗәле булмаган идарә карарлары куркынычы;

Ярдәмче программаны тормышка ашырганда кирәкле координация булмавы куркынычы;

Ярдәмче программадан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр булмавы куркынычы.

Мөмкин булган куркынычларның тискәре йогынтыларын бетерү/ минимальләштерү юллары:

Ярдәмче программаны, Татарстан Республикасы бюджеты акчасын, муниципаль берәмлекләр бюджетлары һәм бюджеттан тыш чыганаклар акчасын җәлеп итеп, федераль бюджет акчасы исәбеннән финанслау варианты;

объектларны адаптацияләү проектларын катгый рәвештә Ярдәмче программаны тормышка ашыру кысаларында төбәкләргә белдерә торган техник йөкләмә таләбе нигезендә килештерүне тикшерүдә тоту. Төбәкләргә белдерелә торган таләпләрнең үтәлешен тикшерүдә тоту буенча эшче төркемнәр төзү;

инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче төркемнәренең тереклек эшчәнлегендәге өстенлекле өлкәләрдә өстенлекле объектларны билгеләүгә һәм аларның сыйфатын билгеләүгә төбәкләрнең бердәм якын килүе.»;

Ярдәмче программаның II бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«II. Ярдәмче программаның максаты, бурычлары, төп көтелә торган соңгы нәтиҗәләре тасвирламасы, аны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары

Ярдәмче программаның максаты булып Татарстан Республикасында инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәренең тереклек эшчәнлегендәге өстенлекле өлкәләрдә өстенлекле объектлардан һәм хезмәтләрдән файдалана алу дәрәҗәсен күтәрү.

Ярдәмче программаның бурычлары:

гражданнарның инвалидлык һәм мөнәсәбәтләрдәге киртәләрне бетерү мәсьәләләрендә хәбәрдар булуы өчен шартлар формалаштыру;

өстенлекле объектлардан һәм хезмәтләрдән файдалана алу торышын бәяләү һәм инвалидларның һәм халыкның аз хәрәкәтләнүче башка төркемнәренең тормышында өстенлекле өлкәләрдәге өстенлекле объектлардан һәм хезмәтләрдән файдалана алуын тәэмин итү буенча норматив хокукый һәм методик база булдыру;

инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәтләнүче башка төркемнәре социаль яклау, сәламәтлек саклау, мәдәният, мәгариф, транспорт, мәгълүмат һәм элемтә, физик культура һәм спорт өлкәсендәге өстенлекле объектлардан һәм хезмәтләрдән тоткарлыксыз файдалана алу өчен шартлар тудыру.

Ярдәмче программаны тормышка ашыруны тасвирлый торган төп күрсәткечләр булып түбәндәгеләр тора:

Татарстан Республикасы өстенлекле объектларының гомуми санында социаль, транспорт, инженерлык инфраструктурасының өстенлекле объектларыннан инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре файдалана ала торган өлеше;

Татарстан Республикасында әлеге хәрәкәт итүче состав (автобус, трамвай, троллейбус) паркында халыкның аз хәрәкәт итүче төркемнәрен йөртү өчен

җиһазландырылган гомуми файдаланудагы автомобиль һәм җир өсте шәһәр электр транспортының хәрәкәт итүче составы паркы өлеше;

системалы рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче 6 яшьтән 18 яшькә кадәрге инвалидларның һәм сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затларның халыкның бу категориясе гомуми санындагы өлеше;

социаль яклау өлкәсендәге өстенлекле объектларның гомуми санында инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре файдалана ала торган социаль яклау өлкәсендәге өстенлекле объектлар өлеше;

Татарстан Республикасында сораштырылган инвалидларның гомуми санында инвалидлар проблемаларына халыкның мөнәсәбәтен уңай бәяләүче инвалидлар өлеше;

эш белән тәэмин итү хезмәте органнары объектларының гомуми санында инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре файдалана ала торган эш белән тәэмин итү хезмәте органнарының өстенлекле объектлары өлеше;

сәламәтлек саклау өлкәсендәге өстенлекле объектларның гомуми санында инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре файдалана ала торган сәламәтлек саклау өлкәсендәге өстенлекле объектлар өлеше;

мәдәният өлкәсендәге өстенлекле объектларның гомуми санында инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре файдалана ала торган мәдәният өлкәсендәге өстенлекле объектлар өлеше;

метро станцияләренең гомуми санында инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре файдалана ала торган метро станцияләре өлеше;

транспорт инфраструктурасы өстенлекле объектларының гомуми санында инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре файдалана ала торган транспорт инфраструктурасы өстенлекле объектлары өлеше;

өстенлекле объектларның гомуми санында инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре файдалана ала торган физик культура һәм спорт өлкәсендәге өстенлекле объектлар өлеше;

мәктәп яшендәге инвалид балаларның гомуми санында сыйфатлы башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алу өчен шартлар тудырылган инвалид балалар өлеше;

5 яшьтән 18 яшькәчә инвалид балаларның гомуми санында әлеге яшьтәге өстәмә белем алучы инвалид балалар өлеше;

мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының гомуми санында инвалид балаларга инклюзив белем алу өчен универсаль киртәсез мохит булдырылган мәктәпкәчә белем бирү оешмалары өлеше;

1,5 яшьтән 7 яшькәчә инвалид балаларның гомуми санында мәктәпкәчә белем ала торган әлеге яшьтәге инвалид балалар өлеше;

гомуми белем бирү оешмаларының гомуми санында инвалид балаларга инклюзив белем алу өчен универсаль киртәсез мохит булдырылган гомуми белем бирү оешмалары өлеше;

Россия Федерациясе субъектындагы белем бирү оешмаларының гомуми санында инвалид балаларга сыйфатлы белем алу өчен шартлар тудырылган белем бирү оешмалары өлеше.

Ярдәмче программаны тормышка ашыру кысаларында Татарстан Республикасында инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәренең тереклек эшчәнлегендәге өстенлекле өлкәләрдә өстенлекле объектлардан һәм хезмәтләрдән файдалана алу дәрәҗәсен күтәрүгә юнәлдерелгән түбәндәге чаралар каралган:

җәмгыятьтәге социаль таркаулыкны бетерү һәм инвалидлар проблемаларына һәм республикада инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре тереклек эшчәнлегенә уңайлы мохит тәэмин итү проблемасына уңай мөнәсәбәт формалаштыру;

Татарстан Республикасында инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре өчен уңайлы мохитнең тотрыклы үсеше шартларын формалаштыру;

Татарстан Республикасында инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәренең тереклек эшчәнлегендәге өстенлекле өлкәләрдә өстенлекле объектлардан һәм хезмәтләрдән файдалана алу шартларын булдырганда дәүләт хакимияте башкарма органнарының, җирле үзидарә органнарының үзара хезмәттәшлеген һәм эшләрен яраштыруны тәэмин итү;

Татарстан Республикасында инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәренең тереклек эшчәнлегендәге өстенлекле өлкәләрдә өстенлекле объектлардан һәм хезмәтләрдән файдалана алу мөмкинлеге турындагы мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру максаты белән җыю һәм системалаштыру;

Ярдәмче программаны тормышка ашыру вакыты: 2014 – 2017 еллар.

2014 – 2015 елларга Ярдәмче программаның максатын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган нәтиҗәләрне җентекләп тасвирлау, шулай ук Ярдәмче программа чараларын финанслау әлеге Ярдәмче программага теркәлгән 1 нче кушымтада китерелә.

2016 елга Ярдәмче программаның максатын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган нәтиҗәләрне җентекләп тасвирлау, шулай ук Ярдәмче программа чараларын финанслау әлеге Ярдәмче программага теркәлгән 2 нче кушымтада китерелә.

2017 елга Ярдәмче программаның максатын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган нәтиҗәләрне җентекләп тасвирлау, шулай ук Ярдәмче программа чараларын финанслау әлеге Ярдәмче программага теркәлгән 3 нче кушымтада китерелә.

2014 – 2016 елларга Ярдәмче программа чаралары исемлеге әлеге Ярдәмче программага теркәлгән 4 нче кушымтада китерелә.

2017 елга Ярдәмче программа чаралары исемлеге әлеге Ярдәмче программага теркәлгән 5 нче кушымтада китерелә.

Ярдәмче программаның 2014 елда федераль бюджеттан һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслана торган объектлары һәм чаралары исемлеге әлеге Ярдәмче программага теркәлгән 6 нчы кушымтада китерелә.

Ярдәмче программаның 2015 елда федераль бюджеттан һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслана торган объектлары һәм чаралары исемлеге әлеге Ярдәмче программага теркәлгән 7 нче кушымтада китерелә.

Ярдәмче программаның 2016 елда федераль бюджеттан һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслана торган объектлары һәм чаралары исемлеге әлеге Ярдәмче программага теркәлгән 8 нче кушымтада китерелә.

Ярдәмче программаның 2017 елда федераль бюджеттан һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслана торган объектлары һәм чаралары исемлеге әлеге Ярдәмче программага теркәлгән 9 нчы кушымтада китерелә.

2014 – 2015 елларга Ярдәмче программаның максатчан күрсәткечләре (индикаторлары) системасы әлеге Ярдәмче программага теркәлгән 10 нчы кушымтада китерелә.

2016 елга Ярдәмче программаның максатчан күрсәткечләре (индикаторлары) системасы әлеге Ярдәмче программага теркәлгән 11 нче кушымтада китерелә.

2017 елга Ярдәмче программаның максатчан күрсәткечләре (индикаторлары) системасы әлеге Ярдәмче программага теркәлгән 12 нче кушымтада китерелә.»;

Ярдәмче программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 804 776,283 мең сум тәшкил итә, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 427 228,883 мең сум, федераль бюджет акчасы исәбеннән – 377 547,400 мең сум.

(мең сум)

| Ел | Гомуми акча күләме | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы | Федераль бюджет акчасы |
|---|---|---|---|
| 2014 | 526 315,883 | 310 526,383 | 215 789,500 |
| 2015 | 121 466,000 | 36 439,800 | 85 026,200 |
| 2016 | 56 496,140 | 16 948,840 | 39 547,300 |
| 2017 | 100 498,26 | 63 313,86 | 37 184,40 |
| Барлыгы | 804 776,283 | 427 228,883 | 377 547,400»; |

2014 – 2017 елларга Ярдәмче программаны ресурслар белән тәэмин итү күләме әлеге Ярдәмче программага теркәлгән 13 нче кушымтада китерелә.

2014 елга Ярдәмче программаны ресурслар белән тәэмин итү күләме әлеге Ярдәмче программага теркәлгән 14 нче кушымтада китерелә.

2015 елга Ярдәмче программаны ресурслар белән тәэмин итү күләме әлеге Ярдәмче программага теркәлгән 15 нче кушымтада китерелә.

2016 елга Ярдәмче программаны ресурслар белән тәэмин итү күләме әлеге Ярдәмче программага теркәлгән 16 нчы кушымтада китерелә.

2017 елга Ярдәмче программаны ресурслар белән тәэмин итү күләме әлеге Ярдәмче программага теркәлгән 17 нче кушымтада китерелә.»;

Ярдәмче программага 3 нче кушымтаны 4 нче кушымта дип санарга;

Ярдәмче программага 3 нче кушымта өстәргә (карарга теркәлә);

Ярдәмче программага 4 нче кушымтаны 6 нчы кушымта дип санарга һәм андагы 1.1 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле 1.1.3 пунктча өстәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «1.1.3 | Шәһәр эчендәге җир асты пассажирлар транспортын һәм хезмәт күрсәтүләрне адаптацияләү | | | |
| | Инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре тоткарлыксыз керә алсын өчен өч метро станциясен адаптацияләү («Яшьлек», «Төньяк вокзал», «Авиатөзелеш») | ТР ТһЮХМ | 0,0 | 0,0»; |

Ярдәмче программага 5 нче кушымтаны 7 нче кушымта дип санарга;

Ярдәмче программага 5 нче кушымта өстәргә (карарга теркәлә);

Ярдәмче программага 6 нчы кушымтаны 8 нче кушымта дип санарга;

Ярдәмче программага 7 нче кушымтаны 10 нчы кушымта дип санарга;

Ярдәмче программага 8 нче кушымтаны 11 нче кушымта дип санарга;

Ярдәмче программага 9 нчы кушымтаны 13 нче кушымта дип санарга һәм аны яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлә);

Ярдәмче программага 9 нчы кушымта өстәргә (карарга теркәлә);

Ярдәмче программага 10 нчы кушымтаны 14 нче кушымта дип санарга;

Ярдәмче программага 11 нче кушымтаны 15 нче кушымта дип санарга;

Ярдәмче программага 12 нче кушымтаны 16 нчы кушымта дип санарга;

Ярдәмче программага 12 нче һәм 17 нче кушымталар өстәргә (карарга теркәләләр).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2017\59.docx